# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Урыс авыл җирлегенең Тулбай торак пунктында 2026 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

26 ноябрь 2025 ел № 2

2025 елның 20 мартындагы № 33-ФЗ «Бердәм җәмәгать хакимияте системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Россия Федерациясе Федераль законының 45 нче һәм 69 нчы маддәләре, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Урыс авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Урыс авыл җирлеге Тулбай торак пунктында халык җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Урыс авыл җирлеге Тулбай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2026 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә (1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугышчан хәрәкәтләр ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында һәм сугышчан хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күпбалалы гаиләләрдән, көндезге формада укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына хезмәткә чакырылган гражданнардан, СВОда катнашучы гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, СВОда катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаилә әгъзаларыннан тыш).

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) Тулбай торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (юлларны кардан чистарту (килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

2) Тулбай торак пунктында Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булып тормаган һәйкәлләрне урнаштыру, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү (катнашучыларга һәм һәлак булган сугышчыларга һәйкәл төзү (төзелеш материаллары сатып алу, хезмәтләр һәм эшләр өчен түләү)).

3. Әлеге карарны Урыс авыл җирлеге мәгълүмат такталарында урнаштырырга, Минзәлә муниципаль районының http://menzelinsk/tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында гамәлдәге законнарга туры китереп бастырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Урыс авыл җирлеге башлыгы И.С. Аксюкова

Совет Урусовского сельского поселения
ИНН 1628002805